**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2025 елның 6 мартындагы 573 номерлы карары**

**Казан шәһәре территориясендә җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен раслау турында**

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җир асты киңлегендә урнашкан инженер-техника тәэмин итү челтәрләрен тиешенчә карап тотуны булдыру максатыннан 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 43 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы кодексының административ хокук бозулар турындагы 3.3 статьясы нигезендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре территориясендә җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка, Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.В.Куляжевка, Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 6 мартындагы
573 номерлы карары белән расланды

**Казан шәһәре территориясендә җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләре**

## I. **Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге кагыйдәләр Казан шәһәренең җир асты киңлекләрендә урнашкан инженерлык коммуникацияләрен тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексын үтәү һәм җәяүлеләрнең гомеренә яисә сәламәтлегенә, транспорт хәрәкәте иминлегенә зыян китерү куркынычы барлыкка килүгә юл куймау максатыннан эшләнде.

1.2. Әлеге кагыйдәләрне гамәлгә ашыру максатыннан түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- балансга тотучы – оештыру-хокукый формага бәйсез рәвештә, аның балансына мөлкәт сакланышы һәм кулланылышы өчен җаваплы нинди дә булса хокукка (хуҗалык белән шөгыльләнү яисә оператив идарә итү килешүе) тапшырылган физик яисә юридик зат;

- хуҗа - оештыру-хокукый формага бәйсез рәвештә милегендә яисә милекнең башка матди яки мәҗбүри хокукында җир асты коммуникацияләре рәвешендәге мөлкәте (шул исәптән милек хокуклары һәм бурычлары) булган физик яисә юридик зат, шәхси эшкуар;

- махсуслаштырылган оешмалар – төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә шәһәр территориясен төзекләндерү өлкәсендәге эшчәнлекнең махсус төрләрен гамәлгә ашыручы төрле оештыру-хокукый формасындагы юридик затлар;

- кое – инженерлык челтәрләрендә, аларны эксплуатацияләгәндә җир асты коммуникацияләре каналларына керүне оештыру өчен билгеләнгән (күзәтү, яңгыр суларын кабул итү, тупик һәм башкалар, шулай ук аларның конструктив элементлары, люкларны, рәшәткәләрне дә кертеп) корылма;

- яңгыр сулары канализациясе – өске (яңгыр, кар сулары), су сиптерү һәм дренаж суларын транспортировкалау өчен билгеләнгән технологик яктан үзара

бәйле инженерлык корылмалары (улаклар, яңгыр суларын тоткыч, лотоклар һәм торбалар) комплексы;

- җир асты коммуникацияләре – инженерлык-техника тәэмин итү челтәрләре: торбаүткәргечләр (хуҗалык-көнкүреш һәм яңгыр канализациясе, җылылык, су һәм газ белән тәэмин итү, су агызу, дренаж, нефть-, газүткәргечләр), коллекторлар, кабель челтәрләре (югары киеренкелек, электр транспорты, урам яктырткычы, начар ток) һәм шәһәр территориясендә булган яки салына торган җир асты инженерлык объектлары, шулай ук аларның конструктив элементлары.

## II. **Җир асты коммуникацияләрен, аларның конструктив элементларын карап тоту һәм эксплуатацияләү**

2.1. Җир асты коммуникацияләренең хуҗалары инженерлык объектларын, аларның конструктив элементларын техник яктан төзек хәлдә тотарга тиеш.

2.2. Җир асты коммуникацияләренең хуҗалары түбәндәгеләр буенча тәэмин итәләр:

1) инженерлык челтәрләрен профилактик тикшерүләрне, агымдагы һәм капиталь ремонтлау эшләрен регламенттагы вакыт аралыгында үткәрү;

2) люк капкачларының, рәшәткәләрнең урнашуына һәм билгеләнешенә карамастан, проект тамгасында (булган очракта) булу яки булмавын даими карау (регламенттагы вакыт аралыгында урынга чыгып тикшерү графиклары буенча), шулай ук коеларны төзек хәлдә тоту һәм аларның ябык килеш урнашуын карап тору;

3) кичекмәстән түбәндәге юллар буенча чаралар күрү:

- ачык, тыгыз ябылмаган, зарарланган яисә җимерелгән коеларның тиешле юл (кисәтүче) тамгалары белән билгеләү һәм киртәләп алу, ГОСТ Р 50597-2017 «Автомобиль юллары һәм урамнар» таләпләре нигезендә аларны алмаштыру яисә торгызу;

- җир асты коммуникацияләренең торышына бәйле рәвештә тиешле юл (кисәтү) тамгалары белән җир убылу, грунт утыру, урам-юл челтәре участокларын билгеләү һәм киртәләп алу, аларны бетерү;

- инженерлык челтәрләрендә аварияләрне бетерү;

4) Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 12 декабрендәге 8023 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре территориясен төзекләндерү белән бәйле җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм

үткәрү турындагы нигезләмәнең таләпләре нигезендә аварияләр нәтиҗәләрен бетерү һәм аларны төзекләндерү барышында бозылган урыннарны торгызу;

5) ремонт һәм авария эшләрендә яңа салына торган асфальт-бетон катнашма маркасын куллану ГОСТ Р 50597-2017 «Автомобиль юллары һәм урамнар», ГОСТ Р 58406.1-2020 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Вак таш-мастлы асфальт-бетон һәм асфальт-бетон катнашмалары. Техник шартлар», ГОСТ Р 58406.2-2020 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Кайнар асфальт-бетон һәм асфальт-бетон катнашмалары. Техник шартлар» һәм башка норматив-хокукый актлар таләпләре нигезендә гамәлдәге өслек маркасыннан түбәнрәк түгел;

6) кирәк булганда контрольлек итүче органнар һәм махсуслаштырылган оешма вәкилләре тарафыннан, кирәкле рөхсәтләр, керү өчен рөхсәтләр рәсмиләштереп, карау коелары люкларына һәм инженерлык челтәрләре белән идарә итү төеннәренә керү;

7) җир асты коммуникацияләреннән алынган барлык төр пычракларны кичекмәстән чыгару.

2.3. Хуҗасыз, файдаланылмый торган җир асты коммуникацияләре, аларның билгеләнешеннән чыгып, билгеләнгән тәртиптә эксплуатацияләүче оешма ачыкланганчы, инженерлык челтәрләренең тиешле төрләрен эксплуатацияләүче җир асты коммуникацияләренең баланс тотучылары тарафыннан тиешле хәвефсез хәлдә тотылырга тиеш.

2.4. Ачык, тыгыз булмаган яки (һәм) ышанычсыз ябылган коелар, рәшәткәләр, җир убылу (җир утыру) табылганда, объектны карап тоту өчен җаваплы оешма, бер тәүлектән дә соңга калмыйча, җир убылу урынын киртәләү буенча кирәкле чаралар күрә, баланс тотучыга хәбәр итә. Объектны (җир кишәрлеген) баланста тотучы җир асты коммуникацияләре хуҗасын ачыклый, җир асты коммуникацияләре хуҗасына, район администрациясенә һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының административ-техника инспекциясе идарәсенә хәбәр итә.

2.5. Люкларның, кое рәшәткәләренең машина юлы, тротуарлар, җәяүлеләр һәм велосипед юллары, яшел зона өслекләре белән тоташуы бер дәрәҗәдә үтәлергә тиеш (тайпылышлар норматив-хокукый документлар таләбе белән билгеләнгән чикләрдә рөхсәт ителә).

2.6. Юлларны, тротуарларны ремонтлаганда коеларның люклары ремонт эшләрен башкаручы оешма тарафыннан камилләштерелгән өслек дәрәҗәсендә куелырга тиеш.

2.6.1. Җир асты коммуникацияләренең норматив булмаган торышы аркасында килеп чыккан юллар, тротуарлар өслегенең бөтенлеге бозылу очраклары коммуникацияләрне баланста тотучы чаралары исәбеннән бетерелә.

2.6.2. Гарантия чорында барлыкка килгән җир убылу, коеларның аска төшеп китүе, төзелеш яки ремонт эшләрен башкаручы оешма тарафыннан үз исәбенә башкарыла.

2.7. Җир асты коммуникацияләрендә планлы эшләрне башкарганда, канализация суларын канализация челтәрендәге якындагы коеларга, ә су үткәргеч суларны һәм җылылык челтәрләреннән килгән суны – яңгыр сулары канализациясенә агызу башкарыла (ул булган очракта һәм кулланучы оешма белән килештерелгән очракта). Юлга су агызу тыела.

2.8. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәренә оешмалар территориясеннән чыккан өслектәге суларны агызу рөхсәт ителми.

2.9. Җир асты коммуникацияләрендәге аварияләр аркасында урам-юл челтәре участокларында су басулар барлыкка килгән очракта, авария нәтиҗәләрен бетерү җир асты коммуникацияләре хуҗалары көче белән башкарыла (юллардагы, тротуарлардагы бозны чабу һәм чыгаруны да кертеп).

2.10. Рөхсәт ителми:

1) җир асты коммуникацияләрен төзү һәм реконструкцияләүне проекттан чигенеп һәм (яисә) корылмаларның ышанычлылыгын һәм озак гомерлелеген киметә торган кондицион булмаган материаллардан башкару;

2) су йоту коелары һәм пар чыгару мәйданчыклары урнаштыру;

3) җир асты коммуникацияләренең төзексезлеге аркасында (инженерлык челтәрләрендәге аварияләрне бетерү чорыннан тыш) урамнарны, биналарны, корылмаларны су басу, су агызудан бозлавык барлыкка килү;

4) газоннарга, тротуарларга, урамнарга һәм ишегалды территорияләренә суны агызу, суырту яки чыгару (әлеге кагыйдәләрнең 2.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш);

5) карны, барлык төр калдыкларны җир асты коммуникацияләренә ташлау;

6) яңгыр суларын кабул итү коеларының чүпләнгән, ләм баскан хәлдә булуы, аларның үткәрү сәләтенең чикләнгәнлеге;

7) хуҗалык-бәдрәф шакшысы канализациясе агынты суларын яңгыр суларына тоташтыру һәм агызу, шулай ук яңгыр сулары агынтысын хуҗалык-бәдрәф шакшысы канализациясенә тоташтыру һәм агызу;

8) ачык коеларның, рәшәткәләрнең булуы, аларның зарарланган яисә җимерелгән халәттә (алар булган очракта) проект билгеләрендә булмавы, шулай ук җир асты коммуникацияләренең узу урыннарында барлыкка килгән

ачык, тыгыз ябылмаган, зарарланган яисә җимерелгән коеларның, җир убылган, грунт утырган, урам-юл челтәре участокларын каплауның киртәләнмәве;

9) җир асты коммуникацияләрендә аварияләрне, аларның нәтиҗәләрен бетерүгә каршы килә торган гамәлләр кылу, шул исәптән аварияләрне бетерүдә файдаланыла торган коелар өстендә һәм аварияләрне бетерү урыннары өстендә автотранспорт калдыру;

10) инженерлык челтәрләренә, җиһазларга, корылмаларга, коммуникацияләргә, аларның җир өсте һәм җир асты өлешләренә зыян китерерү;

11) җир эшләрен башкаруга билгеләнгән тәртиптәге ордер рәсмиләштермичә инженерлык челтәрләре төзү;

12) рөхсәтсез коеларны ачу, инженерлык челтәрләрендә урнашкан ябу җайланмаларын көйләү;

13) гамәлдәге коммуникацияләрдә коеларны грунт, төрле төрдәге калдыклар белән күмү, аларны рөхсәтсез консервацияләү (каты типтагы төрле өслекләрдән файдалануны да кертеп);

14) өслектәге суларны канализация системасына ирекле агызу;

15) рөхсәтсез төзелеш алып бару (тиешле документларны билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштермичә һәм җир асты коммуникацияләре хуҗалары белән килештермичә), сәүдә, хуҗалык һәм көнкүреш корылмаларын, шул исәптән җир асты коммуникацияләренең саклау зоналары чикләрендә стационар булмаган корылмалар урнаштыру;

16) төзелеш чүп-чарын һәм аварияләрне бетерү эшләрен үткәрүгә комачаулаучы башка калдыкларны җир асты коммуникацияләре өстенә өеп кую;

17) инженерлык челтәрләре хуҗаларының килештерүеннән башка, җир асты коммуникацияләренең саклау зоналарында яңа яшел үсентеләр утырту;

18) вәкаләтле оешма башкару документларын рәсмиләштермәгән һәм тапшырмаган килеш, яңа төзелгән инженерлык челтәрләреннән файдалану.

## III. **Кагыйдә таләпләрен бозган өчен җаваплылык**

Кагыйдә таләпләрен үтәмәгән яки бозган өчен хуҗа гамәлдәге законнар нигезендә административ җаваплылыкка тартыла.

---